ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2021 Казан шәһәре № Пр-430/2021

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 4 мартындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар билгеләү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 4 мартындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11-12 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Тәртипнең 1-3 нче кушымталарына ярашлы рәвештә документлар теркәп, Дәүләт комитетына гариза җибәрә.

12. Дәүләт комитеты гариза кергән көннән алып 14 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 нче һәм 3 нче кушымталарында санап үтелгән барлык документларның булу-булмавын, аларның законнар һәм әлеге Тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә.»;

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.С. Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 04.03.2020 № 32
боерыгы белән расланган Сәнәгать
булмаган һәм социаль өлкәләрдә
тарифлар (бәяләр, өстәмәләр,
өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү
тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.06.2021 № Пр-430/2021
боерыгы редакциясендә)

Сәнәгать булмаган өлкәдә тарифлар билгеләү өчен тапшырыла торган документлар исемлеге

1. Җайга салынулы оешма җитәкчесе кул куйган тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим.
2. Тарифлар билгеләү (үзгәртү) кирәклеген нигезли торган аңлатма язуы.
3. Гамәлгә кую документларының күчермәләре.
4. Җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешманың исәпкә алу сәясәте турындагы боерык һәм счетларның эш планы күчермәсе.
5. Эшчәнлек төрләре буенча чыгымнарны бүлү ысулы.
6. Алдагы чор өчен һәм соңгы хисаплылык датасына бухгалтерлык хисаплылыгы (предприятие балансы, Ф-2 «Керемнәр һәм сарыфлар турында»).
7. Тарифларны икътисадый нигезләү өчен сәбәпче булган документларының күчермәләре.
8. Үзкыйммәт калькуляциясе өчен матди, арадаш эшчәнлек чыгымнарын, башка чыгымнарны һәм башка статьяларны аңлату.
9. Хезмәткә түләү фонды исәпләмәсе.
10. Җайга салынулы оешмада гамәлдә булган норматив һәм тармак актлары (тариф килешүе, хезмәт өчен түләү турында нигезләмә, премияләү турында нигезләмә, күмәк килешү, штат расписаниесе, П-4 «Хезмәткәрләр саны, хезмәт хакы һәм хезмәткәрләр хәрәкәте турында мәгълүматлар» һ.б.).
11. Җайга салынулы оешма һәм эшчеләр һәм хезмәткәрләр категорияләре буенча тулаем алганда айлык хезмәт хакы турында белешмә.
12. База чорында төп финанс-икътисад күрсәткечләре турында белешмә.
13. Кирәкле табышны нигезләү.
14. База чорында табыш бүлү турында белешмә.
15. Дәүләт комитеты сайтында Документлар/БДАМС/БДАМС үрнәкләре/Региональ үрнәкләр/Кулланучылар базары адресы буенча урнаштырылган PRIL.TV.TOP.2.16(v2.0) региональ үрнәге <*>.

--------------------------------

<*> Мөрәҗәгать итүчеләргә гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган продукциягә (товарларга) өстәмәләр билгеләү өчен.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 04.03.2020 № 32
боерыгы белән расланган Сәнәгать
булмаган һәм социаль өлкәләрдә
тарифлар (бәяләр, өстәмәләр,
өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү
тәртибенә 3 нче кушымта

Социаль өлкәдә тарифлар билгеләү өчен тапшырыла торган документлар исемлеге

1. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар билгеләү турында тәкъдим.
2. Тарифлар билгеләү (үзгәртү) кирәклеген нигезли торган аңлатма язуы.
3. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар күләме исәпләмәсе.
4. Социаль хезмәтләр күрсәтүгә тарифларны үзгәртүгә йогынты ясый торган күрсәткечләрне анализлау.